| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**СОВЕТ**<br>**Салманского сельского поселения Алькеевского муниципального района** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**Әлкимуниципаль районы**<br>**Салманавылҗирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |
| Адрес: 422874, Республика Татарстан, Алькеевский район, с. Салманы, ул. Молодёжная, д.12.<br>тел: 8 (84346) 72-2-38 | Адресы: 422874, Татарстан Республикасы, Әлки районы,<br>Салманавылы,Яшьләр ур., 12.<br>тел.: 8 (84346) 72-2-38 |


**РЕШЕНИЕ** Салман авылы **КАРАР**

2023 елның 11июле 52№

2023 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлегемилкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында .

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 50 һәм 51 ст., 85 ст. 8 п. 4 пунктчасы, 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлегеУставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлегеСоветы КАРАР ИТТЕ:

1. 1 нче кушымта нигезендә 2023 елга Татарстан Республикасының Әлки муниципаль районына Салман авыл җирлегекараган милекне хосусыйлаштыру планына расларга.

2. 2023 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планын үтәү өчен кирәкле әзерлек чараларын гамәлгә ашырыру максатларындаӘлки муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Россия Федерациясенең «Интернет» челтәрендәге рәсми www.torgi.gov.ru сайтында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Әлкимуниципаль районы
Салман авылҗирлеге
Совет рәисе урынбасары

СОВЕТ САЛМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Д.Н.Нурутдинов

1 нче Кушымта

**2023 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)**

## 1 нче бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2023 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Салман авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. 2023 елда муниципаль милекне хосусыйлаштыру муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, кучемсез милек объектларын тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, муниципаль милекне сатудан бюджет дефицитын каплау чыганакларын булдыруга юнәлдерелгән.

1.3. 2001елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль милекне хосусыйлаштыруны аукционда сату юлы белән башкару күздә тотыла.

## 2 нче бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

2.1. 2023 елда муниципаль казнадагы һәм Әлки муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган оешмалар карамагында булмаган муниципаль милек хосусыйлаштырыла.

2.2.Хосусыйлаштыруга планлаштырыла торган муниципаль милек исемлеге:

| т/б № | Милекнең атамасы һәм характеристикасы | Адрес (урнашу урыны) | Файдалануга тапшыру елы, (чыккан елы) | Хосусыйлаштыруның фаразланган вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Автотранспорт чарасы Машина CHEVROLETNIVA 212300-55 2016 елгы җитештерү Дәүләт номеры Т 843 РА 116 VIN X9L212300H0610568 | Татарстан Республикасы, Әлкимуниципаль районы, Салманавылы, Яшьләрурамы, 12 йорт | 2016 | 3,4 квартал |

## 3 нче бүлек. Муниципаль милекне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү муниципаль мөлкәт

3.1. Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге башкарма комитеты муниципаль милекне хосусыйлаштыру турындагы мәгълүматны оператив рәвештә бирү һәм киңрәк реклама белән тәэмин итү максатыннан әлеге фараз планын үтәү барышында, рәсми мәгълүмат чыганакларыннан тыш, бүтән массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәтеннән дә файдаланырга хокуклы.